КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 октябрь г.Казань № 909

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче; 2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел,

21 май, 380 нче; 2019 ел, 26 март, 221 нче, 2019 ел, 28 май, 445 нче, 2020 ел, 05 февраль, 77 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Аңлатма» бүлегендә:

җиденче абзацта «186» саннарын «188» саннарына алмаштырырга;


унынчы абзацта «37» саннарын «39» саннарына алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «427,420» һәм «6,3» саннарын «464,667» һәм «6,8» саннарына алмаштырырга;

«Әгерҗе муниципаль районы» бүлегендә:

Әгерҗе муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгерҗе муниципаль районы





[1] – Река Иж
[2] – Сложный бор
[3] – Агрызский
[167] – Кичке-Тан
[189] – Пойма реки Кырыкмас
[190] – Красноборский геологический разрез
[200] – Нерестилище стерляди
[207] – Камско-Икский»;

түбәндәге эчтәлекле «Кама-Ык [207]» бүлекчәсен өстәргә:

## «Кама-Ык [207]

| | |
|---|---|
| Статус | Комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы |
| Оештыру документлары | ТР МК 2020 ел, 28 август, 751 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасының Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә һәм Тукай муниципаль районнары |
| Башкарма хакимиятнең контрольлек итүче дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның характеристикасы һәм аның әһәмияте. Гомуми мәйданы 22 290,567 гектар булган тыюлык Татарстан Республикасының Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә һәм Тукай муниципаль районнары территорияләрендә урнашкан.

Тыюлык Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән табигый комплексларны саклау, үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су асты төрләрен саклау максаты белән оештырылды.

Тыюлык территориясе су-сазлык җирләреннән тора, үз эченә борынгы күлләрдән, сазлык массивларыннан, кара ольхадан урманнардан, су асты имәнлекләреннән һәм су асты болыннарыннан тора.


Бу территория берничә су һәм җир асты үсемлекләренең (ак су лилиясе, сары кубышка, сазлык чиләсе, сазлык йөзе, двулистлы любка һ.б.) һәм хайваннар (аккош-шипән, зимородок, соры торна, орлан-аккойрык, саз ташбакасы һ. б.), шул исәптән Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннар яшәү урыны булып тора.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары

белән билгеләнгән тыюлыкны саклау режимы буенча.»;

Актаныш муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Актаныш муниципаль районы




түбәндәге эчтәлекле «Кама-Ык [207]» бүлекчәсен өстәргә:

«Кама-Ык [207]


(кара Әгерҗе районы)»;

түбәндәге эчтәлекле «Агыйдел елгасы дельтасы» бүлекчәсен өстәргә [208]:

«Агыйдел елгасы дельтасы [208]

| | |
|---|---|
| Статус | Комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы |

| | |
|---|---|
| Оештыру документлары | ТР МК 2020 ел, 31 август, 761 нче карары |
| Урнашу урыны | Актаныш муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең контрольлек итүче дәүләт органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның характеристикасы һәм аның әһәмияте. Гомуми мәйданы 14 956,502 гектар булган тыюлык Татарстан Республикасының Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан.

Тыюлык Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән табигый комплексларны саклау, үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су асты төрләрен саклау максаты белән оештырылды.

Тыюлык территориясе су-сазлык җирләреннән тора, үз эченә борынгы күлләрне, сазлык массивларын, кара ольхадан урманнарны, су асты болыннарын ала.


Бу территория берничә су һәм җир асты үсемлекләренең (ак су лилиясе, сары кубышка, сазлык чиләсе, сазлык йөзе, двулистлы любка һ.б.) һәм хайваннар (аккош-шипән, зимородок, соры торна, орлан-аккойрык, саз ташбакасы һ. б.), шул исәптән Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннар яшәү урыны булып тора.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тыюлыкны саклау режимы буенча.»;

«Минзәлә муниципаль районы» бүлегендә:

Минзәлә муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Минзәлә муниципаль районы




[4] – Река Ик
[127] – Река Мензеля
[128] – Игимский бор
[207] – Камско-Иксский»;

түбәндәге эчтәлекле «Кама-Ык [207]» бүлекчәсен өстәргә:


«Кама-Ык [207]

(кара Әгерҗе районы)»;

«Тукай муниципаль районы» бүлегендә:

Тукай муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тукай муниципаль районы




түбәндәге эчтәлекле «Кама-Ык [207]» бүлекчәсен өстәргә:

«Кама-Ык [207]

(кара Әгерҗе районы)»;

3 нче кушымтаның «Чишмә елгасы» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «39 | 39 нчы участок | 55 05 07.7<br>55 05 07.8<br>55 04 43.2<br>55 04 42.4 | 51 14 26.1<br>51 14 27.3<br>51 14 29.7<br>51 14 30.3». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин